РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_26_» ___06___ 2026 ел №663

«2025 – 2027 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында»гы 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, «Физик культура һәм спорт турында»гы 08.10.2008 ел, № 99-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү «Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы 2019 елның 5 мартындагы 159 санлы карары белән, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, спортның культивацияләнә торган төрләрен үстерү өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының спорт абруен күтәрү һәм ныгыту өчен җыелма командалар төзү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасын (алга таба - Программа) раслау турында" 01.04.2025 № 312 карары белән расланган «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында спорт һәм физик культура төрләрен үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортының «Елларга бүлеп Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Елларга бүлеп Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td>
<td>Программаны финанслау муниципаль, республика бюджетлары һәм җәлеп ителгән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.
<table>
<tr><th>Программаны гамәлгә ашыру еллары*</th><th>1 ел / мең сум</th><th>2 ел / мең сум</th><th>3 ел / мең сум</th><th>Барлыгы мең сум</th></tr>
<tr><td>Барлык чыганаклар буенча</td><td>62 946,7</td><td>67 369,3</td><td>65 354,4</td><td>195 670,4</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты акчаларыннан, шул исәптән</td><td>54 439,3</td><td>57 978,7</td><td>62 164,4</td><td>174 582,4</td></tr>
<tr><td>спорт залын оператив идарә итү хокукына беркетүгә бәйле рәвештә муниципаль биремне үтәүне тәэмин итүгә</td><td>0,0</td><td>52,4</td><td>-</td><td>52,4</td></tr>
<tr><td>спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләренә</td><td>1,08</td><td>4,31</td><td>-</td><td>5,39</td></tr>
<tr><td>мөлкәткә салымга</td><td>1 625,9</td><td>2 099,2</td><td>-</td><td>3 725,1</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан, шул исәптән</td><td>4 621,8</td><td>6 143,3</td><td>-</td><td>10 765,1</td></tr>
<tr><td>спорт залын оператив идарә итү хокукына беркетүгә бәйле рәвештә муниципаль биремне үтәүне тәэмин итүгә</td><td>1 197,0</td><td>5 188,2</td><td>-</td><td>6 385,2</td></tr>
<tr><td>спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга</td><td>422,7</td><td>476,1</td><td>-</td><td>898,8</td></tr>
<tr><td>тренер-укытучыларга югары нәтиҗәләр өчен ярдәм итүгә</td><td>260,7</td><td>51,9</td><td>-</td><td>312,6</td></tr>
<tr><td>спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләренә</td><td>106,8</td><td>427,1</td><td>-</td><td>533,9</td></tr>
<tr><td>мөлкәткә салымга</td><td>365,2</td><td>-</td><td>-</td><td>365,2</td></tr>
<tr><td>хезмәт өчен түләү фонды үсешенә</td><td>2 269,4</td><td>-</td><td>-</td><td>2 269,4</td></tr>
<tr><td>Өстәмә җәлеп ителгән акчалар</td><td>3 885,6</td><td>3 247,3</td><td>3 190,0</td><td>10 322,9</td></tr>
</table>
Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.</td>
</tr>
</table>

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.А.Галләмова
8(85593) 2-42-10